ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКУЮКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422741 Республика Татарстан Атнинский район с. Нижний Куюк. Тел. 3-32-47

# КАРАР

12.07.2019 г. № 9

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
бюджетыннан алынучы башка бюджетара
трансфертлар исәбенә башкарылучы
чыгымнар юнәлешен раслау турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсүен стимуллаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 9 апреленнән 102 нче номерлы “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанс тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар тәкъдим итү Тәртибен раслау турында”гы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 14 маддәсенә ярашлы төстә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетыннан алынучы башка бюджетара трансфертлар исәбенә башкарылучы чыгымнар юнәлешен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен расларга.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге җитәкчесе: Мухаметгалиев Ф.Т.